КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 апрель г.Казань № 399

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә базарның планировкасына, планировкасын үзгәртүгә һәм төзүгә, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны һәм андагы бүлмәләрне реконструкцияләүгә и модернизацияләүгә карата таләпләрне раслау турында» 2007 ел, 22 октябрь, 578 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясен үстерү буенча шәһәр төзелешен планлаштыруның территориаль комплекслы схемасын эшләү турында» 1999 ел, 10 апрель, 199 нчы карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә базарның планировкасына, планировкасын үзгәртүгә һәм төзүгә, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны һәм андагы бүлмәләрне реконструкцияләүгә и модернизацияләүгә карата таләпләрне раслау турында» 2007 ел, 22 октябрь, 578 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2006 елның 30 декабрендәге» сүзләрен «2006 елның 30 декабрендәге» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә базарның планировкасына, планировкасын үзгәртүгә һәм төзүгә, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны һәм андагы бүлмәләрне реконструкцияләүгә һәм модернизацияләүгә карата таләпләрдә:

1 бүлекнең беренче абзацында «2006 елның 30 декабрендәге» сүзләрен «2006 елның 30 декабрендәге» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктта «Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» дигән 2.07.01-89* нчы санитария нормалары һәм кагыйдәләре» сүзләрен «42.13330.2016 санитария кагыйдәләре. Кагыйдәләр җыелмасы. Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү. 2.07.01-89* нчы санитария нормалары һәм кагыйдәләренең актуальләштерелгән редакциясе» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктта:

икенче абзацта «иң күбе 75%» сүзләрен «иң күбе 75 процент» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «кимендә 15%» сүзләрен «кимендә 15 процент» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «кимендә 10%» сүзләрен «кимендә 10 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясен үстерү буенча шәһәр төзелешен планлаштыруның территориаль комплекслы схемасын эшләү турында» 1999 ел, 10 апрель, 199 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин